**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 7 маендагы 1396 номерлы карары**

# Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасындагы грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2024 елның 18 декабрендәге 3-35 номерлы «2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү буенча Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетын билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 7 маендагы
1396 номерлы карарына
кушымта

**Хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге тәртип хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) килешүләре нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау өчен шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү процедурасын билгели.

2. Субсидияләр хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) финанс белән тәэмин итү максатыннан шәһәр автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затларга һәм (яки) шәхси эшмәкәрләргә бирелә.

3. Субсидияләр бирү Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты (алга таба – Вәкаләтле орган) тарафыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында Казан шәһәре Думасы карары белән каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен бюджет чараларын алучы буларак Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Тиешле финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында каралган субсидияләр Вәкаләтле органның Татарстан

Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Казан шәһәре территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетында исәпкә алына.

5. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы (алга таба – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

6. Субсидия алучылар сайлап алуда катнашу өчен оешмалар җибәргән тәкъдимнәрне (гаризаларны) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу (алга таба ярашлы рәвештә – гаризалар, сайлап алуда катнашучылар) нәтиҗәләре буенча, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүенә карап һәм гаризаларның керү чиратыннан чыгып, Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

7. Сайлап алу һәм Вәкаләтле органның сайлап алуда катнашучылар белән үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) гамәлгә ашырыла.

8. Сайлап алуда катнашучыларның «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технология хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

9. Сайлап алу критерийлары:

- сайлап алуда катнашучы Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне башкаруга муниципаль контрактлар нигезендә Казан шәһәрендә гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

- сайлап алуда катнашучы Казан шәһәрендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен матди-техник чараларга ия;

- сайлап алуда катнашучы хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда килешүләр төзегән.

10. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны уздыру башланырга 30 календарь көн кала түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- чит ил юридик заты, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр

(алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы аша гамәлгә ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- экстремистлык эшчәнлегенә яки терроризмга катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- БМО Уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары нигезендә махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый акты, башка норматив хокукый актлары нигезендә субсидия бирү планлаштырыла торган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алмый;

- «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яки ул Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- юридик зат булып торган сайлап алуда катнашучы (субсидия алучы) үзгәртеп оештыру (субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булып торган юридик затка башка юридик затны кушу формасында гамәлгә ашырылган үзгәртеп оештырудан тыш), ябылу процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган, ә шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучы (сайлап алуда

катнашучы) шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

- дисквалификацияләнгән затлар реестрында юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки баш бухгалтеры (булган очракта) турында, шәхси эшмәкәр турында һәм субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булган товар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик зат турында белешмәләр юк;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы, шул исәптән Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты алдында акчалата йөкләмәләр буенча түләү вакыты узган (җайга салынмаган) башка бурычы юк.

Сайлап алуда катнашучының әлеге пункт таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерү сайлап алуны уздыруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системасы) белешмәләре нигезендә «Электрон бюджет» системасында, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып (автомат рәвештә тикшерүнең техник мөмкинлеге булганда), автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыру өчен техник мөмкинлек булмаган очракта, катнашучының әлеге пункт таләпләренә туры килү-килмәвен раслау «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында тамгаларны сайлап алуда катнашучы тарафыннан электрон рәвештә билгеләп кую аша башкарыла.

Билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслауда субсидия алучы җаваплы.

11. Сайлап алуны уздыру турында игълан Вәкаләтле орган тарафыннан «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, формалаштырылган көннән алып бер календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда бастырып чыгарыла.

Игълан түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

- сайлап алуны уздыру вакыты;

- сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итә башлау һәм кабул итүне тәмамлау көннәре һәм вакыты, шул ук вакытта гаризаларны кабул итүне

тәмамлану көне сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

- Вәкаләтле органның атамасы, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

- Вәкаләтле орган сайтының домен исеме һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) сәхифәләр күрсәткечләре;

- әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүләрен раслау өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

- әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучылар туры килергә тиешле сайлап алу критерийлары;

- әлеге Тәртипнең 13, 14 пунктлары нигезендә сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру тәртибе һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр;

- әлеге Тәртипнең 16, 22 пунктлары нигезендә гаризаларны кире алу, гаризаларны кире кайтару, шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгеләү тәртибе, гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

- әлеге Тәртипнең 18-21 пунктлары нигезендә гаризаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

- гаризаларны кире кагу тәртибе, шулай ук аларны әлеге Тәртипнең 23 пункты нигезендә кире кагу нигезләре турында мәгълүмат;

- әлеге Тәртипнең 16 пункты нигезендә гаризаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

- субсидия күләмен исәпләүнең әлеге Тәртипнең 33 пункты белән билгеләнгән тәртибе;

- әлеге Тәртипнең 17 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү тәртибе, аңлатмалар бирүнең башлану һәм тәмамлану көне;

- әлеге Тәртипнең 29 пункты нигезендә сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) субсидия бирү турындагы килешүне (алга таба – килешү) имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

- әлеге Тәртипнең 32 пункты нигезендә сайлап алуның җиңүчесен (җиңүчеләрен) килешү төзүдән баш тарткан (баш тартканнар) дип тану шартлары;

- бердәм порталда һәм Вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге https://kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/komitet-potransportu/konkursy/ рәсми

сайтында (алга таба – Вәкаләтле органның рәсми сайты) сайлап алуга нәтиҗә ясау беркетмәсен урнаштыру вакыты, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмый;

- субсидия бирүнең әлеге Тәртипнең 38 пункты белән билгеләнгән нәтиҗәсе.

Сайлап алуны уздыру турындагы игъланга үзгәрешләр кертү, түбәндәге шартларны үтәп, сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кабул итү тәмамланган көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла:

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү вакыты мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән алып гаризаларны кабул итү тәмамланган көнгә кадәр күрсәтелгән вакыт кимендә өч календарь көн тәшкил итәрлек итеп озайтыла;

- сайлап алуны уздыру турында игъланга үзгәрешләр кертелгәндә, сайлап алу ысулын үзгәртү рөхсәт ителми;

- сайлап алуны уздыру турында игъланга үзгәрешләр гаризалар кабул итү башланган көннән соң кертелгән очракта, сайлап алуны уздыру турында игъланга сайлап алуда катнашучыларның гаризаларга үзгәрешләр кертә алу хокукын күздә тоткан нигезләмә өстәлә;

- гариза тапшырган сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турында игъланга үзгәрешләр кертү хакында, сайлап алуны уздыру турында игъланга үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасы аша хәбәр ителә.

12. Бердәм порталда сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында Вәкаләтле орган тарафыннан игълан урнаштыру сайлап алуда катнашучыларның гаризалар тапшыру вакыты тәмамлану көненә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

Сайлап алу уздыруны гамәлдән чыгару турында игълан «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштырыла, Вәкаләтле орган җитәкчесенең (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турындагы мәгълүматны үз эченә ала.

Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Вәкаләтле органга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире кайтарып алу сайлап алуны юкка чыгару очрагы булып тора.

Гариза тапшырган сайлап алуда катнашучыларга сайлап алу уздыруны гамәлдән чыгару турындагы мәгълүмат «Электрон бюджет» системасы аша хәбәр ителә.

Сайлап алу бердәм порталда аны гамәлдән чыгару турында игълан урнаштырылган көннән гамәлдән чыгарылган дип санала.

Әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару вакыты тәмамланганнан соң һәм сайлап алуда җиңүче белән килешү төзелгәнгә кадәр Вәкаләтле орган Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә каршы тора алмаслык хәл барлыкка килгән очракта гына сайлап алуны гамәлдән чыгарырга мөмкин.

13. Сайлап алуда катнашучы гаризаны сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән вакыт эчендә «Электрон бюджет» системасындагы веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә формалаштыра һәм юллый, «Электрон бюджет» системасына түбәндәге документларның электрон күчермәләрен (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларны) тапшыра:

- гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә лицензияләнә торган эшчәнлек төрләре башкарылганда, хуҗалык эшчәнлеген башкаруга лицензия;

- Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны башкаруга муниципаль контрактларның (килешүләрнең) булуын раслый торган документ;

- лизинг түләүләре графиклары белән хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр;

- сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмавын яки аның Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмавын раслый торган документлар.

Юридик зат тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә түбәндәгеләр тапшырыла:

а) гамәлгә кую документларының һәм аларга кертелгән барлык үзгәрешләрнең күчермәләре;

б) җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар.

Шәхси эшмәкәр тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә шәхси эшмәкәр паспорты күчермәсе (беренче бит һәм теркәлү

тамгасы булган битләр), шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында теркәлү турында язма күчермәсе) тапшырыла.

Гаризада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат һәм документлар;
- сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган атамасы;
- сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры;
- салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;
- салым органында исәпкә кую көне һәм коды;
- юридик зат адресы;
- юридик яктан әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен элемтә телефоны номеры, почта адресы һәм электрон почта адресы;
- сайлап алуда катнашучының җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры, вазифасы);
- сайлап алуда катнашучының гамәлгә кую документлары нигезендә сайлап алуда катнашучы гамәлгә ашырырга хокуклы төп һәм өстәмә эшчәнлек төрләре исемлеге;
- субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;
- сайлап алуда катнашучы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган гариза турында мәгълүмат, шулай ук сайлап алуда катнашучы турында тиешле сайлап алу һәм субсидия бирү нәтиҗәсе белән бәйле, «Электрон бюджет» системасында веб-интерфейсның тиешле экран формаларын тутыру юлы белән тапшырыла торган башка мәгълүматны «Интернет» челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Вәкаләтле органның файдалана алу мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле белешмәләр булган очракта (сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны Вәкаләтле органга үз инициативасы белән тапшырырга әзер булган очрактан тыш), Вәкаләтле органга сайлап алуда катнашучыдан әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан документлар һәм мәгълүмат тапшыруны таләп итү тыела.

Гаризага теркәлә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре документны тулысынча яки аның фрагментын мәгълүматны карау өчен һәркем файдалана ала торган программа тәэминаты чаралары белән карау

мөмкинлеген тәэмин итүче киң таралган ачык форматларга ия булырга һәм аларның эчтәлеге белән махсус программалар чараларыннан яисә технологик чаралардан башка танышырга мөмкинлек бирми торган чаралар белән шифрланган яки сакланган булырга тиеш түгел.

14. Гариза сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Россия Федерациясе законнары нигезендә гаризада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы җаваплы.

15. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган гаризага «Электрон бюджет» системасында теркәлү номеры куелган көн сайлап алуда катнашучының гариза тапшыру датасы булып санала.

16. Сайлап алуда катнашучы гаризаны сайлап алуны уздыру тәмамланган көнгә кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы гаризалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат гариза бирергә хокуклы.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан гаризага үзгәрешләр кертү яки гаризаны кире кайтарып алу сайлап алуда катнашучының гариза бирү тәртибенә охшаш тәртиптә башкарыла.

Гаризаларны эшләп бетерү өчен сайлап алуда катнашучыларга кире кайтару каралмаган.

17. Сайлап алуның теләсә кайсы катнашучысы, бердәм порталда сайлап алу үткәрелү турында игълан урнаштырылган көннән башлап гаризалар тапшыру тәмамланырга өч эш көне кала, «Электрон бюджет» системасында тиешле мөрәҗәгатне формалаштырып, Вәкаләтле органга сайлап алуны уздыру турында игълан нигезләмәләрен аңлату белән бәйле өчтән артык булмаган санда сорау җибәрергә хокуклы.

Вәкаләтле орган сайлап алуны уздыру турында игълан нигезләмәләренә аңлатманы күрсәтелгән игълан белән билгеләнгән вакытта, әмма гаризалар тапшыру тәмамланырга бер эш көне кала, «Электрон бюджет» системасында тиешле аңлатманы формалаштыру юлы белән җибәрә. Сайлап алуны уздыру турындагы игълан нигезләмәләренең аңлатмалары аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

18. Вәкаләтле орган тарафыннан гаризаларны карап тикшерү «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле органга гаризаларны карап тикшерү мөмкинлеге ачылган көннән соң килә торган 10 эш көне эчендә гамәлгә

ашырыла.

Вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында игълан белән билгеләнгән гаризалар тапшыру вакыты тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча ачыла.

«Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган тарафыннан гаризалар бирү вакыты тәмамланганчыга кадәрге көн билгеләнергә мөмкин, ул узганнан соң Вәкаләтле органга «Электрон бюджет» системасында сайлап алуда катнашучылар тапшырган гаризаларны карап тикшерү мөмкинлеге ачыла.

19. Вәкаләтле орган, сайлап алуны уздыру турында игълан белән билгеләнгән гаризаларны ачу көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, сайлап алуда катнашу өчен тапшырылган гаризалар турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган гаризаларны ачу турында беркетмәне имзалый:

а) гаризаны теркәү номеры;

б) гаризаның керү көне һәм вакыты;

в) сайлап алуда катнашучының тулы атамасы;

г) юридик зат адресы.

20. Гаризаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә төзелә һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, имзаланган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

21. Сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм гаризаны кире кагу өчен нигезләр булмаса, гариза карап тикшерелергә тиешле дип таныла.

Гаризаның сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килүе хакындагы карар Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда катнашучы тапшырган гариза составында бирелгән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләрен алган көнне кабул ителә.

Кабул ителгән гаризаларны ранжирлау аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

22. Сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын кире кайтару өчен нигезләр:

1) гаризада сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты имзасы юк;

2) катнашучы тарафыннан ике һәм аннан күбрәк гариза җибәрү, шул ук вакытта алдан бирелгән гаризалар әлеге катнашучы тарафыннан кире алынмаган

очракта. Әлеге очракта катнашучыга мондый сайлап алуда катнашу өчен тапшырылган барлык гаризалар кире кайтарыла.

23. Гаризаны карап тикшерү барышында гаризаны кире кагу өчен нигезләр:

а) сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртипнең 10 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килми;

б) сайлап алуны үткәрү турында игъланда күрсәтелгән документлар тапшырылмаган (тулы күләмдә тапшырылмаган);

в) сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган гаризалар һәм (яки) документлар сайлап алуны уздыру турында игълан белән билгеләнгән таләпләргә туры килми;

г) әлеге Тәртипнең 10 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан сайлап алуда катнашучы тарафыннан гариза составында тапшырылган документлардагы мәгълүмат дөреслеккә туры килми;

д) сайлап алуда катнашучы гаризаны гаризалар бирү өчен билгеләнгән көннән һәм (яки) вакыттан соң тапшырылган.

24. Вәкаләтле орган тарафыннан гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, гаризаларны карап тикшерү вакыты тәмамланган көннән алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, кабул ителгән һәм карап тикшерелгән гаризаларның саны турында мәгълүматны, шулай ук сайлап алуда катнашучы һәр зат буенча гаризасы карап тикшерелергә тиешле дип тану яисә, кире кагу нигезләрен күрсәтеп, гаризасын кире кагу турында мәгълүматны үз эченә алган гаризаларны карап тикшерү турында беркетмә төзелә.

25. Гаризаларны карап тикшерү турында беркетмә гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре нигезендә автомат рәвештә бердәм порталда формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аны имзалаган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

26. Сайлап алу түбәндәге очракларда узмаган дип таныла:

а) гаризалар бирү вакыты тәмамлану көненә бер гариза да тапшырылмаган;

б) гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык гаризалар кире кагылган.

27. Әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган сайлап алуда катнашучы сайлап алуның җиңүчесе дип таныла.

28. Сайлап алуны тәгәлләү һәм сайлап алу җиңүчесен ачыклау максатыннан сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсе төзелә. Сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсе сайлап алу җиңүчесен билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Вәкаләтле орган җитәкчесенең (аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аны имзалаган көннән соң килә торган эш көненнән дә соңга калмыйча, – бердәм порталда һәм, сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Вәкаләтле органның рәсми сайтында урнаштырыла.

Беркетмәгә түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

- гаризаларны карап тикшерү көне, вакыты һәм урыны;

- гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның сайлап алу уздыру турында игъланның кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

- килешү төзелә торган субсидия алучы атамасы һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

Сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләрне кертү сәбәпләрен күрсәтеп, аны формалаштыруның әлеге пункт белән билгеләнгән тәртибенә охшаш тәртиптә яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга нәтиҗәләр ясау беркетмәсенең беренче версиясе имзаланган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

29. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алу җиңүчесе билгеләнгәннән соң, Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе әмере белән билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә сайлап алу җиңүчесе белән ун календарь көн эчендә килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ формасында төзелә һәм һәр як исеменнән эш йөртергә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле имзасы белән имзалана.

30. Килешү түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

- субсидия бирүнең күләме, максаты, шартлары һәм тәртибе;

- субсидияне күчерү вакыты;

- субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап һәм субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләрне бирү тәртибе, вакыты һәм

формалары;

- пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган оешманың үзе тарафыннан сатып алынган автобусларны башка затларга милеккә мәҗбүри бирүне һәм үзе тарафыннан сатып алынган автобусларга ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукын тапшыруны килешү төзелгән көннән алып биш ел дәвамында Вәкаләтле орган белән килештерү турында йөкләмәсе;

- бюджет чараларын алучы буларак төп бүлүчегә килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки, яңа шартлар буенча килештерүгә ирешелмәгәндә, килешүне өзү турында;

- субсидия алучының, субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашкан җәмгыятьләрдән, устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашкан коммерция оешмаларыннан тыш) үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәүне тикшерүгә ризалыгы турында;

- чит илдән югары технологияле җиһазлар, чимал һәм комплектлаучы эшләнмәләр сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле Тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына субсидия алучылар – юридик затлар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан чит ил валютасы алуны тыю турында.

Кирәк булган очракта, Вәкаләтле орган субсидия алучы белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Субсидия алучы юридик затны кушу, кушылу яки үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүгә йөкләмәдә затны алмаштыру өлешендә, хокуклар күчә торган юридик затны күрсәтеп, өстәмә килешү төзү юлы белән

үзгәрешләр кертелә.

Субсидия алучы юридик затны бүлү, бүлеп чыгару рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук субсидия алучы юридик зат юкка чыгарылганда яки субсидия алучы шәхси эшмәкәр эшчәнлеге туктатылганда, килешүне берьяклы тәртиптә өзү турында хәбәрнамә һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен тиешле бюджетка кире кайтару турында мәгълүматны күрсәтеп, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт формалаштырып, килешү өзелә.

31. Сайлап алу җиңүчесенең сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән таләпләргә туры килмәү яки сайлап алу җиңүчесенең дөрес булмаган мәгълүмат тапшыру факты ачыкланган очракта, Вәкаләтле орган сайлап алу җиңүчесе белән килешү төзүдән баш тарта.

32. Субсидия алучы, сайлап алуны уздыру турында игъланда күрсәтелгән вакыт эчендә килешүне субсидия алучы исеменнән эш йөртү хокукына ия зат тарафыннан имзалауны тәэмин итмәгән очракта, килешү төзүдән баш тарткан дип таныла.

33. Субсидия күләме (P) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$P = \sum^{m} \text{N}х\text{К}_{авт}\ х\ 34\%,$$ биредә:

N – бер автобус өчен лизинг түләүләренең уртача айлык күләме, ул 288 922 сумга тигез, ләкин финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүгә лизинг түләүләрен каплау графигы белән билгеләнгән айлык лизинг түләве күләменнән артмый, сумнарда;

$К_{авт}$ – хәрәкәттәге составны финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизингка алынган автобуслар саны, берәмлекләрдә;

m – субсидия алучы тарафыннан билгеләнгән лизинг түләүләрен башкару айлары саны.

34. Субсидия бирү нәтиҗәсе – хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизинг түләүләрен башкаруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплау.

35. Пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы субсидияләр бирү нәтиҗәлелегә күрсәткече (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) булып тора, ул транспорт чараларын

линиягә чыгару коэффициенты кебек күрсәткеч ярдәмендә бәяләнә. Әлеге күрсәткеч кыйммәте 2025 елның 1 октябренә кадәр >=0,7, 2025 елның 1 октябреннән соң >= 0,8 булырга тиеш.

Агымдагы елда транспорт чараларын линиягә чыгару коэффициенты ($К_{вып}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_{\,вып} = \sum Q_{фактвыпуск} / \sum Q_{планвыпуск},$$ биредә:

$Q_{фактвыпуск}$ – хәрәкәттәге составны финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизингка сатып алынган автобусларны линиягә фактта чыгару;

$Q_{планвыпуск}$ – хәрәкәттәге составны финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизингка сатып алынган автобусларны линиягә Казан шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны башкаруга муниципаль контрактлар нигезендә билгеләнгән план буенча чыгару.

2025 елның 1 октябреннән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы өстәмә күрсәткеч – даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында транспорт чараларының фактта рейслар башкару коэффициенты ($К_{рейс}$) ярдәмендә бәяләнә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_{рейс} = \frac{Q_{фактрейс}}{Q_{планрейс}},$$ биредә:

$Q_{фактрейс}$ – хәрәкәттәге составны финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизингка сатып алынган автобуслар тарафыннан башкарылган рейсларның факттагы саны;

$Q_{планрейс}$ – муниципаль контракт нигезендә расписание белән билгеләнгән рейсларның план буенча саны. Хәрәкәттәге составны финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизингка сатып алынган автобуслар тарафыннан пассажирлар йөртү һәм багаж ташу әлеге муниципаль контрактка ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында транспорт чараларының фактта рейслар башкару коэффициенты ($К_{рейс}$) күрсәткече >= 0,75 булырга тиеш.

36. Субсидия субсидия алучы тарафыннан Вәкаләтле органга субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән формалар буенча тапшырылган түбәндәге документлар нигезендә ай саен бирелә:

1) килешү белән билгеләнгән форма буенча субсидия алуга гариза;

2) хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизинг түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны (чыгымнарның бер өлешен) каплауга субсидия күләмен исәпләү;

3) хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләр нигезендә лизинг түләүләрен гамәлгә ашыруга чыгымнарны раслый торган документларның күчермәләре;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә документлар тапшыру көненә 30 календарь көннән артык булмаган вакыт эчендә барлык дәрәҗәләрдәге Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлары булмавын раслый торган документларның күчермәләре. Бурычы булган очракта, гариза бирүче әлеге бурычны гариза бирү көненә тулысынча каплавы турындагы түләү йөкләмәләре күчермәләрен бирергә хокуклы.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучы тарафыннан расланырга һәм аларга мөһер (булган очракта) сугылырга тиеш.

37. Каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнарга хәрәкәттәге составны (автобусларны) финанс белән бәйле арендалау (лизинг) буенча 2025 елда төзелгән килешүләргә лизинг түләүләре графигы белән билгеләнгән, әмма күләме әлеге Тәртипнең 33 пунктында китерелгән формула буенча исәпләнгәннән артык булмаган лизинг түләүләре керә.

38. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 33 пунктында күрсәтелгән документларны терки һәм документларны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә аларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүне кире кагу турында карар кабул итә. Субсидия бирү турындагы карар субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән форма буенча рәсмиләштерелә.

39. Вәкаләтле орган субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә субсидия алучылар тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына шәхси счетыннан акча күчерә.

40. Субсидияләр бирүне кире кагу өчен нигезләр:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 36 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты ачыклану.

Субсидия алучыларның субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру һәм, Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булу яисә күрсәтелгән акчаларны, аларга ихтыяҗ булмаганда, хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта кире кайтару (кирәк булганда) турында карар кабул ителгән очракта, мондый нигезләмәләрне килешүгә кертү мөмкинлеге бар.

41. Субсидия алучы «Электрон бюджет» системасында субсидия бирү турында килешү белән билгеләнгән форма буенча квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның унынчы эш көненнән дә соңга калмыйча, – нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисап, субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, еллык хисап тапшыра.

Вәкаләтле орган хисапларны кабул итә һәм субсидия алучы тарафыннан хисаплар тапшырылган көннән башлап биш эш көне эчендә аларны тикшерә.

42. Пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра торган оешма үзе тарафыннан сатып алынган автобусларны башка затларга милеккә мәҗбүри бирүне һәм үзе тарафыннан сатып алынган автобусларга ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукын тапшыруны субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән алып биш ел дәвамында Вәкаләтле орган белән килештерү буенча йөкләмәләрне кабул иткән очракта, субсидияләр бирелә.

43. Субсидияләр сайлап алуда җиңүчеләр арасында әлеге Тәртипнең 2 пункты белән каралган максатка агымдагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләре тулысынча бүленеп беткәнче гаризалар тапшыру чираты нигезендә бүленә.

44. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән шартларның үтәлмәве Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән башлап 30 эш көне эчендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты keременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

45. Акчаларны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты керемenә үз теләге белән кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә 30 көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

46. Субсидияләр алучыларга – юридик затларга, шулай ук субсидияләр

алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы башка юридик затларга, чит илдән югары технологияле җиһазлар, чимал һәм комплектлаучы эшләнмәләр сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле операцияләрдән, Тәртип белән билгеләнгән башка операцияләрдән тыш, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акча хисабына чит ил валютасы сатып алу тыела.

47. Субсидия алучылар, субсидияләр алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затлар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән тыш) үзләренә карата бюджет акчаларын баш бүлүче тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерү үткәрүгә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгын бирергә тиеш.

48. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерү үткәрә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен бәяләү мөмкин булмаган очракта, урынга чыгып тикшерү үткәрелә. Субсидия алучы контроль өчен керү мөмкинлеген тәэмин итәргә, шулай ук күчмә тикшерү барышында субсидия бирү белән бәйле соратылган документларны тапшырырга тиеш.

49. Субсидияләр алучылар тарафыннан Вәкаләтле органга тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучының тиешле вазифаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

50. Субсидия акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдалану, шулай ук субсидия алу максатыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә субсидия алучыга йөкләнә.

51. Бюджет акчаларын файдалануны Вәкаләтле орган контрольдә тота.

___________________